**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Олы Бортас авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**2018 елның 4 сентябре** **№ 79**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Бортас авыл җирлеге Советының 2017 елның 14нче ноябрендәге “Җир салымы турында”гы 59 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексы, “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Бортас авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Бортас авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Бортас авыл җирлеге Советының 2017 елның 14нче ноябрендәге “Җир салымы турында”гы 59 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. карарның 6нчы маддәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“6нчы маддә. Салым базасын киметү
Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә салым базасын (салымны тотып калуны) киметү салым түләүченең сайлавы буенча бер җир кишәрлегенә карата башкарыла.
Сайланган җир кишәрлеге турындагы мөрәҗәгать (ул кишәрлектән салым тотып калу кулланыла), салым түләүче тарафыннан үзенең теләге белән салым органына, салым чоры булган елның 1нче ноябренә кадәр тапшырыла. Шул чордан башлап күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата салымны тотып калу кулланыла”.
2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:
- Татарстн Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Олы Бортас авылы, Ленинград ур., 27нче йорт;
- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Балчыклы авылы, Ленин ур., 70нче йорт, шулай ук Кама Тамагы муниципаль районы рәсми порталының хокукый мәгълүматының һәм рәсми сайтының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Олы Бортас авыл җирлеге Башлыгына Р.С. Сәгдиевка йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Бортас авыл җирлеге Башлыгы,**
**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Бортас авыл җирлеге Советы рәисе** **Р.С. Сәгдиев**